# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеген Күлле-Киме торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“16” ноябрь 2019 ел. № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 16 ноябрендә «Сез 2020 елда Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Күлле-Киме авылында җирлек территориясен чистарту һәм төзекләндерү
- урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү
- урам юлларының асфальт катламын ремонтлау һәм транспорт өчен түләү
- урам су-үткәргечләрен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 264 (ике йөз алтмыш дүрт) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 173 (йөз җитмеш өч) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 173 (йөз җитмеш өч) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучылар 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2020 елда Күлле-Киме авыл җирлеге Күлле-Киме торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия